КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 сентябрь г.Казань № 814

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инновация сәясәтенең нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 19 ноябрь, 894 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген һәм интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән идарә итү өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.1 нче пунктында:

беренче абзацта «инвестиция» сүзеннән соң «һәм инновация» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген һәм интеллектуаль милек өлкәсен үстерү»;

2 бүлекнең 2.1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1.10 нчы пунктча өстәргә:

«2.1.10. Интеллектуаль милек булдыру, аның сакланышын тәэмин итү, интеллектуаль милеккә хокукларның булуын тәэмин итү һәм аны яклау өчен шартлар формалаштыру.»;

3 бүлектә:

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән идарә итү (01.11.01*).»;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

энергия һәм ресурларны саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешен җайга салу (03.05*);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешен билгеләнгән тәртиптә җайга салу (этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүдән һәм аларны әйләнештә йөртүдән тыш) (03.05.02*);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (04.01*);

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02*);

Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт комплексы белән идарә итү функциясен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.16*);

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);

Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.13*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһаздан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү (01.07.01*);

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.07.03*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

мәгариф белән идарә итү (04.05*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән туристлык өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09*);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.18*);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (04.03.03*).»;

4 бүлекнең 4.1 нче пунктында:

4.1.31 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.31. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген һәм интеллектуаль милек өлкәсен үстерү мәсьәләләре буенча вәкаләтле Татарстан Республикасы органы буларак федераль башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек итә.»;

4.1.33 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.33. Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган инновация һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алга таба тормышка ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыруны тәэмин итә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 19 июль, 605 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Кодификаторның «Тармакара идарә» 01 функция кодының «Өченче» графасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | «01.11.01 | Интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән идарә итү». | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин